## ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Түбән Табын авыл җирлеге Югары Табын торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20 ноябрь 2021 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2021 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2022 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Югары Табын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000 (өч мең) сум күләмендә, ә Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә ризамы:

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
2. Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.
3. Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.
4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.
5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.
6. Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.
7. Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.
8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.
9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.
10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.
11. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 248 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 129, бу 52% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 101 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 28 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим униципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең Югары Табын торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Югары Табын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000 (өч мең) сум күләмендә, ә Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү.
2. Халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.
3. Физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми спорт чараларын үткәрүне оештыру.
4. Җирлекнең рәсми мәдәни-массакүләм чараларын үткәрүне оештыру.
5. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.
6. Җирлек чикләрендә урам-юл челтәре элементларына, планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү.
7. Каты коммуналь калдыкларны туплау һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу.
8. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту.
9. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны оештыру.
10. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге.
11. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру.

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы** _______ **(имза)** **Р.Ш. Кыяметдинов** **(имзаның аңлатмасы)**